**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Курай Елга торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**02 ноябрь 2023 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сукаеш авыл җирлеге Курай Елга торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВО да катнашучыларны , көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдән 200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- "Дулкын чишмәсе" чишмәсен төзекләндерүгә чыгым материаллары сатып алу

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сукаеш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында түбәндәге адреслар буенча: Зур Сукаеш авылы, Совет ур. 30 йорт, Курай Елга авылы, Курай елга ур. 22-23 йорт, һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы Закирова З.Җ.